РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Майскогорского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423565, Нижнекамский район,
п. Трудовой, ул. Школьная, 11

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Майская Горка авыл жирлеге
Советы

423565, Түбән Кама районы, Трудовой
поселогы, Мэктэп урамы, 11

тел./факс (8555) 33-57-17, электронный адрес: Mayskogorsko.sp@tatar.ru, сайт: www. majskogorskoe-sp.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

от 14.11.2023 г. № 18

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Майская Горка авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2018 елның 23 июлендәге 18 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлегенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Майская Горка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Майская горка авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Майская Горка авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2018 елның 23 июлендәге 18 номерлы карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Карарның 2 пунктындагы 1 пунктчасының өченче абзацында «бирелгән» һәм «, дача» сүзләрен төшереп калдырырга;

Карарның 3.1 пунктның алтынчы абзацында «мәйданы 30 квадрат метрдан артмаган» сүзләрен төшереп калдырырга;

Карарның 3.1 пунктындагы җиденче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә игълан итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «СОВЕТ МАЙСКОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» ИНН 1630003154

А.П. Морозов